**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**

# КАРАР

«06» июня 2024 ел Яр Чаллы № 67

Икеайлык нәтиҗәләре буенча Тукай муниципаль районы авыл җирлекләре территорияләрендә төзекләндерү өлкәсендә таләпләрнең үтәлешен тикшерү буенча комиссия төзү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, авыл җирлекләре карарлары белән расланган Авыл җирлекләре территорияләрендә төзекләндерү кагыйдәләре, «Тукай районы территориясен төзекләндерү, яшелләндерү һәм санитар чистарту буенча язгы чаралар үткәрү турында» район Башкарма комитеты Җитәкчесенең 2024 елның 22 мартындагы 753 номерлы карары нигезендә

## КАРАР БИРӘ:

1. Авыл җирлекләре территорияләрендә төзекләндерү, чисталык һәм тәртип саклау өлкәсендә таләпләрнең үтәлешен тикшерү буенча эшче комиссия төзергә.
2. Эшче комиссия составын расларга (1 кушымта).
3. Комиссиягә район авыл җирлекләре территорияләрендә төзекләндерү торышы критерийлары буенча бәяләү үткәрергә һәм тикшерү нәтиҗәләрен раслау өчен Тукай муниципаль районы Башлыгына тапшырырга (2 кушымта).
4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Муниципаль район Башлыгы
вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Р.И. Закиров

Тукай муниципаль районының 2024 елның 6 июнендә 67 номерлы карарына 1 кушымта

Авыл җирлекләре территорияләрендә төзекләндерү, чисталык һәм тәртип саклау өлкәсендә таләпләрнең үтәлешен тикшерү буенча эшче комиссия составы

**Рәис:**
Закиров Р.И. – Тукай муниципаль районы Башлыгы вазыйфаларын вакытлыча башкаручы – комиссия рәисе;

**Комиссия секретаре:**
Мадярова Д.Ә. – Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш һәм халык яшәешен тәэмин итү бүлеге баш белгече.

**Комиссия әгъзалары:**

1. Хәкимова И.Ф. – район Советы аппаратының оештыру бүлеге башлыгы;
2. Васильева А.П. – район Советы аппаратының оештыру бүлеге баш белгече;
3. Зәкиев Р.М. – «ТАТМЕДИА» ААҖ филиалы директоры – «Якты юл» («Светлый путь») газетасы редакциясе баш редакторы.